| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» | | «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.03.2022 г.Лениногорск № 175

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 9 августында «Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан яңа редакциядә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 728 номерлы карары белән расланган Төзелеш планлаштыру турындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгән шәхси торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм җир кишәрлегендә шәхси торак төзелеше объекты яки бакча йорты урнаштыру мөмкинлеге турында хәбәрнамәләр җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 декабрендәге 476-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 9 августында «Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан яңа редакциядә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 728 номерлы карары белән расланган Төзелеш планлаштыру турындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгән шәхси торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм җир кишәрлегендә шәхси торак төзелеше объекты яки бакча йорты урнаштыру мөмкинлеге турында хәбәрнамәләр җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.5.1 пунктта «шәхси торак төзелеше объектын төзү яки реконструкцияләү» сүзләрен «шәхси торак төзелеше объектын төзү, реконструкцияләү («Күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешле төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп, индивидуаль торак төзелеше объектларын төзүдән тыш»)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны рәсми публикатор - «Лениногорские вести» газетасында бастырырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru), гражданнар күзәтү өчен мөмкин булган мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче З. Г. Михайлова

Л.М. Галимова
5-18-52